БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 11 2020 ел № 326

«2021 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»

«Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга расларга:

1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5кә тигез итеп.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 19 11
326 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (1 укучыга бер елга сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | Башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Бию сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Бию сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |